
Тарихи ядкарьләребезне барлап



Әбелгазый Баһадир хан. Шәҗәрәи төрек / Төз. М. Әхмәтҗанов, Ә. Сабирова. – Казан, 2007. – 271 б.

Әбелгазый ханның «Шәҗәрәи төрек» (Төркиләрнең шәҗәрәсе) исемле хезмәте фән дөньясында XVIII йөздән билгеле булса да, бүгенге татар укучысына үз телендә бик үк таныш әсәр түгел.

Әбелгазый Баһадир хан (1603-1663) үз заманының иң укымышлы шәхесләреннән саналырга мөмкин. Аның «Шәҗәрәи төрек» әсәре күп кенә тарихи фактларны ачыкларга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, татар кабиләләренең кайдан килеп чыкканлыгы, аларның X-XI гасырлардан килгән тарихлары турында. Кайбер кабилә атамаларын хәзерге вакытта да татар шәҗәрәләрендә очратып була. Китапта Алтын Урда тарихы, Нугай Урдасы оешуы хакында бай информация теркәлгән. Гомумән, бу әсәр — Үзәк Азия һәм Көнчыгыш Ауропа халыкларының, шул исәптән татарларның да этник тарихына уникаль мәгълүмат җиткерә торган чыганак.

Әбелгазый Баһадир хан үз заманасының тарихи-гыйльми өлкәсенең артта калуына борчыла. Аныңча, вакыйгаларны, килешүләрне, дәүләт һәм хакимият эшчәнлеген барлау мөһим, чөнки киләсе буыннар үткән турындагы мәгълүматны шундый язмалардан алачак. Моннан башка, һәрбер кеше үзенең кардәшлеген белү өчен шәҗәрәсен саклап калырга тиеш.

Югарыда телгә алынган китапның кереш мәкаләсендә М. И. Әхмәтҗанов бүгенге татар укучысының мондый басмага ихтыяҗы булуын ассызыклап әйтә. М. Әхмәтҗанов һәм Ә. Сабирова тарафыннан «Шәҗәрәи төрек»нең татар телендәге яңа басмасы хәзерләнгәндә асыл текст итеп Г. Фәезхановның «Тарихы шәҗәрәи төрек» (1891) басмасы алынган. Моннан башка, китапны төзүчеләр 1906 елда Казанда чыккан «Шәҗәрәи төрек»нең Г. С. Саблуков тарафыннан башкарылган рус теленә тәрҗемәсен һәм 1992 елда Ташкентта үзбәк телендә дөнья күргән басмасын да файдаланганнар. Төзүчеләр Г. Фәезханов басмасындагы тел кытыршылыкларын һәм техник хаталарны төзәтү, текстта очраган кеше исемнәренең язылышын унификацияләү буенча зур эш башкарганнар.

Бу хезмәт тарихчы, филолог, фольклорчы, этнографлар һәм башка фән вәкилләре тарафыннан, һичшиксез, тәкъдир ителәчәк. Телгә алынган китап киң катлау укучы өчен дә кызыклы булыр.

Гөлнара Зәйниева,
филология фәннәре кандидаты

РЕЗЮМЕ

Рецензия кандидата филологических наук Г. Зайнеевой на известное сочинение хивинского хрониста XVII в. Абулгази Бахадур хана «Шәҗәрәи төрек» (Родословное древо тюрков), подготовленное к изданию на татарском языке М. Ахметзяновым и А. Сабировой.

EV_1_08.indb 217 13.05.2008 12:20:48